СОВЕТ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
422060, Республика Татарстан, Сабинский район,
п.г.т. Богатые Сабы, ул. Г.Закирова, 52

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ
422060, Татарстан Республикасы, Саба районы,
Байлар Сабасы ш.т.п., Г.Закиров урамы, 52 йорт

тел. (84362) 2-31-33, 2-31-44, факс (84362) 2-31-74, e-mail: saba@tatar.ru, www.saby.tatarstan.ru

№ 128 от 21.02.2022
на № _________от ______________

# КАРАР

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советының “Саба муниципаль районының җирле үзидарә органнарында командировкага җибәрү тәртибе турында Нигезләмәне раслау хакында” 2010 елның 19 февралендәге 289 номерлы карары белән расланган Саба муниципаль районы җирле үзидарә органнарында командировкага җибәрү тәртибе турында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 166 статьясы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Хезмәткәрләрне хезмәт командировкаларына җибәрү үзенчәлекләре турында» 2008 елның 13 октябрендәге 749 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советы КАРАР БИРДЕ:

**1.** Саба муниципаль районы Советының «Саба муниципаль районының җирле үзидарә органнарында командировкага җибәрү тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау хакында» 2010 елның 19 февралендәге 289 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешне кертергә:

**1.1.** 2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә».

**2.** Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советының «Саба муниципаль районының җирле үзидарә органнарында командировкага җибәрү тәртибе турында Нигезләмәне раслау хакында» 2010 елның 19 февралендәге 289 номерлы карары белән расланган Саба муниципаль районы җирле үзидарә органнарында командировкага җибәрү тәртибе турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешне кертергә:

**2.1.** 2 пунктта «хезмәт командировкаларына ... буенча» сүзләреннән соң «язмача» сүзен өстәргә;

**2.2.** 8 пунктны түбәндәге редакциядә бирергә:

«8. Хезмәткәрнең командировка урынында булуының фактттагы вакыты хезмәт командировкасыннан кайткач хезмәткәрләргә бирелә торган юл йөрү документлары буенча билгеләнә.

Хезмәткәр эш бирүченең язма карары нигезендә командировка урынына һәм (яисә) кире эш урынына хезмәт транспортында , хезмәткәр милкендәге яисә өченче зат

милкендәге транспортта (ышанычнамә буенча) киткән/кайткан очракта, командировка урынында булуның факттагы вакыты хезмәт язуында күрсәтелә. Ул хезмәткәр тарафыннан эш бирүчегә командировкадан кайткач, күрсәтелгән транспортның командировка урынына бару һәм кире кайту өчен файдалануын раслаучы документлар белән бергә тапшырыла. (юллама кәгазе, маршрут кәгазе,исәп-хисап кәгазьләре квитанцияләр, касса чеклары һәм транспорт йөреше маршрутын раслый торган башка документлар).

Юл документлары булмаган очракта, хезмәткәрнең командировкада булуының факттагы вакытын хезмәткәр командировка урынындагы торак урынын яллау документлары белән раслый. Кунакханәдә яшәгән очракта күрсәтелгән булу вакыты Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 1997 елның 25 апрелендәге 490 номерлы «Россия Федерациясендә кунакханә хезмәтләре күрсәтү кагыйдәләрен раслау турында» карары белән расланган Россия Федерациясендә кунакханә хезмәтләре күрсәтү кагыйдәләрендә каралган белешмәләр булган командировка урыны буенча кунакханә хезмәтләре күрсәтүгә шартнамә төзүне раслый торган квитанция (талон) яисә башка документ белән раслана.

Юл документлары, торак урыны наемы буенча документлар яисә командировка урыны буенча кунакханә хезмәтләре күрсәтүгә шартнамә төзүне раслый торган башка документлар булмаганда, хезмәткәр командировка урынында булуының факттагы вакытын раслау максатларында хезмәт запискасы һәм (яисә) хезмәткәрнең командировкада булуының фактик вакыты турында документ тапшырыла, анда хезмәткәрнең командировка урынына (командировка урыныннан) килү вакыты турында кабул итүче якның (оешманың яисә вазыйфаи затның) раслануы була.».

**2.3.** 15 пунктта «200» санын «300» санына алмаштырырга, «300» санын «700» санына алмаштырырга.

**3.** Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының Хокукый мәгълүматлар турындагы http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында бастырып чыгарырга.

Саба муниципаль
районы Башлыгы Р.Н. Минниханов